# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сокман торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**23.10.2024** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сокман торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 23 октябрендә 11:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сокман торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, хатын, балигъ булган балалар) тыш , яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән **500** сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Сокман авылындагы килешү буенча электрик эшенә хезмәт күрсәтү һәм аның эшенә түләү һәм урам яктыртуын тоту буенча башка чыгымнарны);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларга хезмәт күрсәтү (кар чистарту), Сокман авылына үлән чаптыру, МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт хакы түләү һәм Сокман авылы территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар);

- су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (сантехник һәм чыгым

материалларын сатып алу, сууткәргеч челтәрне ремонтлау һәм су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 58 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 32 кеше, бу 55 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 32 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сокман торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сокман торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, хатын, балигъ булган балалар) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән **500** сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Сокман авылындагы килешү буенча электрик эшенә хезмәт күрсәтү һәм аның эшенә түләү һәм урам яктыртуын тоту буенча башка чыгымнарны);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларга хезмәт күрсәтү (кар чистарту), Сокман авылына үлән чаптыру, МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт хакы түләү һәм Сокман авылы территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар);

- су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (сантехник һәм чыгым

материалларын сатып алу, суүткәргеч челтәрне ремонтлау һәм су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Салимуллин

Совет Табарлинского сельского поселения
Тәбәрле авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002519
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ